РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«1» март 2021 с. Тюлячи № 83

Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының 2021 елга максималь күләмен билгеләү турында

«Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакын билгеләү методикасы, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Россия Федерациясе буенча 2021 елның беренче яртыеллыгына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2021 елның 1 кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/пр номерлы боерыгы, Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 50, 51 статьялары нигезендә, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының 2021 елга максималь күләмен түбәндәгечә билгеләргә:

1.1. Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләме:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 37353,43 сум;

1.1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – һәр гаилә әгъзасына 23770,36 сум;

1.1.3. Өч һәм аннан да күбрәк кешедән торган гаилә өчен – һәр гаилә әгъзасына 20374,60 сум.

1.2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме:

1.2.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен – 1779327 сум;

1.2. Ике кешедән торган гаилә өчен – 2264598 сум;

1.2.3. Өч кешедән торган гаилә өчен – 2911626 сум;

1.2.4. Дүрт кешедән торган гаилә өчен – 3882168 сум;

1.2.5. Биш кешедән торган гаилә өчен – 4852710 сум;

1.2.6. Алты кешедән торган гаилә өчен – 5823252 сум;

1.2.7. Җиде кешедән торган гаилә өчен – 6793794 сум;

1.2.8. Сигез кешедән торган гаилә өчен – 7764336 сум.

2. Җирле үзидарә органнарына әлеге карарның 1.1 һәм 1.2 пунктларында күрсәтелгән чик күрсәткечләрне, торак урыннарына мохтаҗлар буларак исәпкә куелганда, кулланырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http:pravo.tatarstan.ru һәм Теләче муниципаль районының рәсми сайтында халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары Ф.С. Вәлиевка йөкләргә.

Җитәкче И.Х. Хәмидуллин

Татарстан Республикасы
Теләче муниципаль районы
Башкарма комитетының
«___» _______ 2021 № ____
карарына кушымта

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм 2021 елга салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләмен билгеләү методикасы**

1. Социаль наем шартнамәләре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарын бирү нормасы буенча торак урыннар алуның базар хакының исәп-хисап күрсәткече (алга таба - хисап күрсәткече) түбәндәге формула буенча исәпләнә:

СЖ = НП х РС х РЦ,

биредә:

СЖ - базар бәясенең исәп-хисап күрсәткече яки мөлкәт хакының иң чик күрсәткече;

НП - гаиләнең бер әгъзасына торак урыны бирү нормасы;

РС - гаилә әгъзалары саны;

РЦ - Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан расланган, Татарстан Республикасында торак урыны алу өчен түләүсез субсидияләр исәпләү өчен башкарма хакимиятнең тиешле федераль органы тарафыннан билгеләнгән гомуми мәйданның бер квадрат метрының уртача базар бәясеннән артмаган, муниципаль берәмлекнең уртача шартларына һәм коммуналь хезмәтләр белән тәэмин ителешенә туры килә торган торак урыны мәйданының бер квадрат метрының уртача исәпләнгән исәп-хисап бәясе (2021 елның беренче кварталына - 53 919 сум).

а) ялгыз яшәүче граждан өчен: СЖ = 53919 х 33 = 1779327 сум;

б) ике кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53919 х 42 = 2264598 сум;

в) өч кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53919 х 18 х 3 = 2911626 сум;

г) дүрт кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53919 х 18 х 4 = 3882168 сум;

д) биш кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53919 х 18 х 5 = 4852710 сум;

е) алты кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53919 х 18 х 6 = 5823252 сум;

ж) җиде кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53919 х 18 х 7 = 6793794 сум;

з) сигез кешедән торган гаиләгә: СЖ = 53 919 х 18 х 8 = 7764336 сум.

2. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендә булган һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының максималь күләме СЖ исәпләү күрсәткеченә тигез итеп кабул ителә.

Граждан гаиләсенең һәр әгъзасына туры килә торган уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме билгеләнә:

- торак урын сатып алуга ипотека кредиты алу мөмкинлеге булган шәһәрләрдә - һәр гаилә әгъзасына туры килә торган, СЖ исәпләү бәясе буенча торак урын сатып алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керем дәрәҗәсеннән чыгып, түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$ПД = 0,7 \times СЖ \times ПС / (1 - (1 + ПС)^{-КП}) / (0,25 \times РС),$$

биредә:

ПД - гаиләнең һәр әгъзасына туры килә торган һәм СЖ исәп-хисап бәясе буенча торак урыны алу өчен агымдагы шартларда банкта ипотека кредиты алу өчен кирәкле уртача айлык җыелма керемнең максималь күләме;

СЖ - исәп-хисап күрсәткече;

ПС - бер ай эчендә кредит буенча процент ставкасы (унарлы вакланма); (Россия Федерациясе Үзәк банкы ставкасы елына 4,25%, ягъни аена 4,25/100/12 = 0,0035);

КП - бөтен кредит срогына кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (айлар саны);

РС - гаилә әгъзалары саны;

0,7 - кредит суммасы һәм фатир бәясе чагыштырмасы;

0,25 - кредит буенча түләүнең гаилә айлык җыелма кереме белән чагыштырмасы.

Торак урынының гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар бәясе Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Россия Федерациясе буенча 2021 елның беренче яртыеллыгына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының бәясе нормативы һәм Россия Федерациясе субъектлары буенча 2021 елның 1 кварталына торак урынның гомуми мәйданының бер квадрат метрының уртача базар хакы күрсәткечләре турында» 2020 елның 24 декабрендәге 852/пр номерлы боерыгы белән Татарстан Республикасы буенча 53919 сум күләмендә билгеләнгән.

**Гаиләнең һәр әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең максималь күләмен исәпләү**

1 номерлы таблица

| 12 | СЖ-торак бинаны сатып алуның базар бәясе (СЖ = РС х РЦ х НП)(сум.) | РС- гаилә әгъзалары саны (кеше) | РЦ- 1 кв. м торак бинаның базар бәясе (сум.) | ПС- кредит буенча айлык процент ставкасы, % | КП - кредит буенча түләүләрнең гомуми саны (ай) | Кредит суммасы һәм фатир бәясенең чагыштырмасы | Кредит буенча түләүнең җыелма айлык кереме белән чагыштырмасы | ПД- максималь керем (сум) (бер кешегә) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | 53 919 | 4,25/100/12=0,0035 | 180 | 0,7 | 0,25 | |
| 33 | 1779327 | 1 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,25 | 37353,43 |
| 42 | 2264598 | 2 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,5 | 23770,36 |
| 54 | 2911626 | 3 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 0,75 | 20374,60 |
| 72 | 3882168 | 4 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 1 | 20374,60 |
| 90 | 4852710 | 5 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 1,25 | 20374,60 |
| 108 | 5823252 | 6 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 1,5 | 20374,60 |
| 126 | 6793794 | 7 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 1,75 | 20374,60 |
| 144 | 7764336 | 8 | 53 919 | 0,0035 | 180 | 0,7 | 2 | 20374,60 |